ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Сирин Батыршин урамы, 33йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№ 14** **13 апрель 2026 ел**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитар - экологик икеайлык үткәрү турында**

Торак пунктлар территорияләрен санитар чистартуны, яшелләндерүне һәм төзекләндерүне тәэмин итү һәм халыкның экологик һәм санитар-эпидемиологик иминлеге таләпләренә җавап бирә торган аларның торышын китерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 елның 19 мартындагы «Татарстан Республикасы торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык үткәрү турында»гы 462-р санлы күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә:**

1. 2026 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Кәрәкәшле авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык (алга таба икеайлык) игълан итәргә;
2. Икеайлыкны оештыру һәм үткәрү буенча комиссия төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта);
3. Барлык милек рәвешләрендәге оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләренә план нигезендә икеайлык чараларын үткәрүне тәкъдим итәргә.
4. 2026 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр санитар-экологик хәлне яхшырту чаралары планын (2 нче кушымта) расларга.
5. Җитәкчеләргә, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларга, учреждениеләргә 3 нче кушымта нигезендә беркетелгән территорияләр нигезендә территорияләрне чистартуны тәкъдим итәргә.
6. Әлеге карарны Кәрәкәшле авыл җирлегенең махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: М.Н.Мусин

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елның 13 апрелендәге 14 санлы карарына 1 кушымта

**Икеайлыкны оештыру һәм уздыру комиссиясе составы**

1. Мусин Марат Наил улы – Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы;
2. Исхакова Эльвира Фатыйх кызы – 1 санлы Кәрәкәшле авылы сайлау округы депутаты, Кәрәкәшле авылы мәдәният йорты мөдире;.
3. Нәбиуллин Данияр Ильдус улы – 2 санлы Кәрәкәшле авылы сайлау округы депутаты, Кәрәкәшле ҖЧҖ директоры;
4. Шәрәфиева Зөлфия Марс кызы – Кәрәкәшле төп гомуми белем бирү мәктәбе МБББУ директоры;
5. Гиздетдинова Гүзәл Сәгадәтулла кызы – “Ләйсән” МБМББУ мөдире;
6. Нәбиуллин Илдус Мәгъсүм улы – Нәбиуллин И.М. КФХ башлыгы;
7. Шәрифуллина Лилия Ринат кызы –Салкын-Чишмә авылы клубы мөдире;
8. Зарипова Альбина Сәләхетдин кызы – Урал бистәсе авыл клубы мөдире;
9. Хәмидуллина Гөлнара Минсәгыйть кызы – "Шәрәфиева Сәлимә Шәмсетдин кызы исемендәге Кәрәкәшле авылы туган якны өйрәнү музее" МБУ музее караучысы

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елның 13 апрелендәге 14 санлы карарына 2 кушымта

**Каракашлы авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен санитар чистарту буенча чаралар планы**

| № п/п | Чаралар атамасы | Вакыты | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Төзекләндерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыелышлары, авыл җирлеге Советы утырышын үткәрергә | 2026 елның 1 апреленә кадәр | Авыл җирлеге башлыгы |
| 2 | Сәүдә нокталарының янәшәдәге территорияләрендә санитария нормаларын үтәүне тикшерүне оештырырга һәм системалы рәвештә башкарырга | һәрдаим | Авыл җирлеге башлыгы, полициянең участок уполномоченные |
| 3 | Полиция участок уполномоченные белән берлектә ТР санитария һәм табигатьне саклау законнарын бозуларны ачыклау һәм булдырмау буенча рейдлар үткәрергә | Айга 2 тапкыр | Авыл җирлеге башлыгы, полициянең участок уполномоченные |
| 4 | Юл буе полосаларын җыештыру | һәрдаим | Авыл җирлеге башлыгы |
| 5 | Торак пунктлар эчендәге баганаларны агарту | 1 майга кадәр | Авыл җирлеге башлыгы |
| 6 | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан учреждениеләр, оешмалар биналарының фасадларын ремонтлау | 01.04.2026 31.05.2026 | учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләре |
| 7 | Йортларның фасадларын ремонтлау | 01.04.2026 31.05.2026 | Торак урыннарның милекчеләре, яллаучылары |
| 8 | Һәйкәлләрне һәм обелискларны төзекләндерү | 1 майга кадәр | Мәдәният хезмәткәрләре |
| 9 | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратлар территорияләрен төзекләндерү | 01.05.2026 31.05.2026 | Зират караучысы |
| 10 | Авыл җирлеге территориясендәге чишмәләрне төзекләндерү | һәрдаим | Авыл җирлеге башлыгы |
| 11 | Җирлекнең торак пунктларында яшел үсентеләр утырту | 01.05.2026 31.05.2026 | Авыл җирлеге башлыгы |
| 12 | Терлекчелек фермалары һәм машина-трактор паркы территорияләрен санитар чистарту | һәрдаим | Авыл хуҗалыгы формированиеләре җитәкчеләре |
| 13 | Санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү | до 15.05.2026 | Авыл җирлеге башлыгы |

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елның 13 апрелендәге 14 санлы карарына 3 кушымта

| № п/п | Предприятиеләр, оешмалар атамасы | Беркетелгән территория | Телефон номеры һәм җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Администрация ( башкарма комитет) | Администрациянең якын-тирә территориясе,Сирин Батыршин урамыннан Мирфатыйх Зәкиев урамына кадәр | 4-21-21 Мусин Марат Наил улы |
| 2 | “Кәрәкәшле” ҖЧҖ | МТФ территориясе, складлар, үзәк гараж | 4-72-09 Нәбиуллин Ланияр Илдус улы |
| 3 | Кәрәкәшле төп гомуми белем бирү мәктәбе МБББУ | Мәктәп яны территориясе, Мирфатыйх Зәкиев урамыннан Комсомол урамына кадәр | 4-21-22 Шәрәфиева Зөлфия Марс кызы |
| 4 | “Ләйсән” Кәрәкәшле авылы балалар бакчасы МБМББУ | Балалар бакчасы янындагы территория, Нариман урамы | 4-21-86 Гиздетдинова Гүзәл Сәгадәтулла кызы |
| 5 | "Шәрәфиева Сәлимә Шәмсетдин кызы исемендәге Каракашлы туган якны өйрәнү музее" МБУ | Габбасов урамы | 4-21-31 Хәмидуллина Гөлнара Минсәгыйть кызы |
| 6 | «Ак мәчет” Кәрәкәшле авылы мәчете | Мәчет яны территориясе | 89870946478 Төхбәтуллин Марсель Җәмил улы |
| 7 | 1.Кәрәкәшле авыл мәдәният йорты,<br>2.Кәрәкәшле китапханәсе,<br>3.Почта элемтәсе бүлекчәсе. | Авыл мәдәният йорты яны территориясе Вахитов урамы,<br>Тукай урамы,<br>Комсомол урамы<br>Каран-Чишмә урамы<br>Көчле-Елга урамы | 4-21-06<br>1.Исхакова Эльвира Фатыйх кызы<br>2. Әхмәтова Ирина Михайловна<br>3. Камилова Рәмзия Рафаэль кызы |
| 8 | Кәрәкәшле авылы ФАП | Якын-Тирә территория | 4-21-09 Фәттахова Миләүшә Кәбир кызы |
| 9 | 1.Салкын-Чишмә авылы клубы<br>2. Салкын-Чишмә авылы китапханәсе<br>3. Салкын-Чишмә авылы ФАП | Салкын-Чишмә авылы, Фрунзе урамы, Чапаев урамы, Ак-Чишмә авылы | 4-21-73<br>1.Шәрифуллина Лилия Ринат кызы<br>2.Ибраһимова Зәгинә Мәҗит кызы<br>3.Гимаева Энже Насих кызы |
| 10 | Салкын-Чишмә авылы мәчете | Мәчет яны территориясе | 89172496235 Мөхәмәдиев Дамир Мансур улы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11 | «Нәбиуллин» КФХ | Администрация яны территориясе (МТФ, складлар, үзәк гараж территориясе) | 4-72-09<br>Нәбиуллин Илдус Мәгъсүм улы |
| 12 | 1.Урал бистәсе ФАП<br>2.Урал бистәсе клубы | Урал бистәсе (Урал урамы, Көнчыгыш урам, Юл буе урамы) | 4-72-61<br>1.Рәхманова Зөлфия Фәрит кызы<br>2.Зарипова Альбина Сәләхетдин кызы |
| | | | |